**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

30.06.2023 № 218

**2023–2024 еллар чорына алар тарафыннан электр энергиясен куллану режимын чикләү икътисадый, экологик, социаль нәтиҗәләргә китерүге мөмкин булган электр энергиясен (куәтен) кулланучылар исемлеген раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 4 маендагы 442 номерлы боерыгы белән расланган Электр энергиясен куллану режимын тулысынча һәм (яисә) өлешчә чикләү кагыйдәләренең 15, 15[1] пунктлары нигезендә:

1. 2023–2024 еллар чорына алар тарафыннан электр энергиясен куллану режимын чикләү икътисадый, экологик, социаль нәтиҗәләргә китерүге мөмкин булган электр энергиясен (куәтен) кулланучыларның кушымтада бирелгән исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «2022–2023 еллар чорына алар тарафыннан электр энергиясен куллану режимын чикләү икътисадый, экологик, социаль нәтиҗәләргә китерүге мөмкин булган электр энергиясен (куәтен) кулланучылар исемлеген раслау турында» 2022 елның 30 июнендәге 216 номерлы боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**